РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ
НОВОТИНЧАЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯҢА ТИНЧӘЛЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

«15» октябрь 2018 ел № 60-1

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районы Яңа Тинчәле авыл җирлеге Советының
2018 елның 29 сентябрендәге 59-1 номерлы
карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Тинчәле авыл җирлеге Советы

**КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:**

I. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Тинчәле авыл җирлеге Советының 2018 елның 29 сентябрендәге 59-1 номерлы «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Тинчәле авыл җирлеге советы карарына үзгәрешләр кертү хакында» карарына (2015 елның 21 маендагы 1-64 номерлы, 2015 елның 07 октябрендәге 2-1 номерлы, 2018 елның 20 июнендәге 53-1 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне һәм өстәмәләрне кертергә:

**1. Карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

« «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2014 елның 14 ноябрендәге 1-49 номерлы Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Яңа Тинчәле авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында»;

**2. Преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Яңа Тинчәле авыл җирлеге Советы»;

**3. II пунктны түбәндәге редакциядә үзгәртергә һәм бәян итәргә:**

«II. Әлеге карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, ләкин http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми басылып чыккан һәм урнаштырылган көннән алып 1 айдан да иртәрәк булмаган вакытта.».

II. Әлеге карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә, ләкин http://pravo.tatarstan.ru/, шулай ук Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре

Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://buinsk.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми басылып чыккан һәм урнаштырылган көннән алып 1 айдан да иртәрәк булмаган вакытта.

III. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы Буа муниципаль
районының Яңа Тинчәле авыл җирлеге башлыгы Р.К. Мадышев